Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты

Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты
**КАРАРЫ**

16 июнь, 2023 ел № 14

«Белешмәләр (өземтәләр) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 17 мартындагы 5 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Белешмәләр (өземтәләр) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Кибәч авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 17 мартындагы 5 номерлы карары белән расланган белешмәләр (өземтәләр) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (2022 елның 31 октябрендәге 17 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктындагы унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризаны формаль-логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан һәр кырның электрон формасы тутырылганда, автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон рәвештәге гариза бирүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән турыдан-туры гаризаның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Кибәч авыл җирлеге башлыгы Р.Ә. Рәимов